Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан халыклары телләре турында

### Кереш елеш

Бу Закон Татарстан Республикасы халыкларын, аларның мәдәниятләрен һәм телләрен һәрьяклап үстерү, җәмгыятьнең җәмгыяви-икътисади һәм рухи-әхлакый алга китешендә һәр халыкның иҗади куәтен, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен мөмкин кадәр күбрәк куллану, кеше хокукларын гамәлгә ашыру зарурлыгына нигезләнеп эшләнә.

Татарстан Республикасында нинди дә булса телгә карата дошманлыкны һәм түбәнсетүне пропагандалау рөхсәт ителми, кайсы телне куллануына карап теләсә нинди кимсетүләр, шул исәптән һөнәр буенча чикләүләр тыела.

Әлеге Закон рәсми мөнәсәбәтләрдә телләрнең кулланышын хокукый көйләүгә нигез булып тора.

### I БУЛЕК
### Теп тешенчәләр

1 маддә. Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасының законнар җыелмасы

Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасының законнар җыелмасын әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары тәшкил итә.

2 маддә. Телләрне куллану иреге

Татарстан Республикасы территориясендә һәр халыкка һәм шәхескә туган телен саклау һәм һәрьяклап үстерү өчен дәүләт тарафыннан шартлар тудырыла, аралашу телен сайлауда һәм куллануда ирек тәэмин ителә.

3 маддә. Телләрнең хокукый халәте

1. Дәүләт Татарстан республикасындагы барлык халыкларның телләре саклану һәм үсүе өчен тигез хокукларны таный. Дәүләт республикадагы барлык халыкларның телләрен үз яклавына ала.

2. Татарстан Республикасында тигез хокуклы ике дәүләт теле: татар һәм урыс телләре кулланышта йөри.

3. Татар һәм урыс милләтеннән булмаган халыкларның күпләп яшәгән урыннарында рәсми аралашу өлкәсендә, татар һәм урыс телләре белән бергә, әлеге төбәктә яшәүче халык теле дә кулланылырга мөмкин. Мондый урыннарда телләр кулланылышының тәртибен Татарстан Республикасы законнары билгели.

4 маддә. Татарстан Республикасы халыклары телләрен яклауның гарантияләре

1. Татарстан Республикасы халыклары телләре дәүләт тарафыннан яклана. Телләрнең статусына бәйсез рәвештә, дәүләт органнары аларның җәмгыяви,икътисади һәм юридик яклanышын тәэмин итәләр.

2. Телләрне җәмгыяви яклау Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклауга, үстерүгә һәм өйрәнүгә, аларның тигез хокуклылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән. фәнни нигездәге тел сәясәте үткәрүне күз алдында тота.

3. Телләрне икътисади яклау Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт һәм фәнни программаларны бюджеттан максатчыл һәм башка төрле финанслауны,

һәм шуларны гамәлгә ашырганда льготалы салым сәясәте уздыруны шарт итеп куя.

4. Телләрне юридик яклау телләр турында законнар җыелмасын бозган өчен юридик һәм физик затларны җаваплылыкка тартуны күз алдында тота.

5 маддә. Татарстан Республикасы гражданнарының телне белү-белмәүләренә бәйсез рәвештә хокукларын гарантияләү

I. Дәүләт Татарстан Республикасы гражданнарының төп сәяси, икътисади, иҗтимагый һәм мәдәни хокукларын аларның теге яки бу телне белү-белмәүләренә бәйсез рәвештә гамәлгә ашыруны гарантияли.

2. Телне белү яисә белмәү Татарстан Республикасы гражданнарының телләргә хокукларын чикләүнең нигезе була алмый. Халыкларның һәм шәхеснең телләргә хокукларын бозучылар Закон нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

6 маддә. Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм куллану өлкәсендә Татарстан Республикасының компетенциясе

Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм куллану өлкәсендә Татарстан Республикасы, аның дәүләт хакимияте һәм идарәсенең югары дәүләт органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасы законнары җыелмасы;

татар һәм урыс телләренең дәүләт телләре буларак тигез хокуклы яшәешен тәэмин итү;

республикада кулланыла торган башка телләрнең үсеше өчен шартлар тудыру.

Татарстан Республикасы читтә яшәүче татарларга һәм башка мил-

ләт вәкилләренә татар телен сакларга, үстерергә һәм өйрәнергә ярдәм итә.

7 маддә. Татарстан халыкларының телләрен үстерүнең дәүләт программалары

1. Татарстан халыкларының телләрен саклау, үстерү һәм өйрәнү буенча Татарстан Республикасының дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана. Программаны билгеләнгән вакытта гамәлгә ашыруны башкарма хакимият органнары тәэмин итә.

Барлык дәрәҗәдәге бюджетларны төзегәндә Татарстан халыкларының телләрен үстерү программасын финанслау күз алдында тотыла.

2. Телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы Татарстан халыклары телләрендә әдәбият бастырып чыгару, бу өлкәдә фәнни эзләнүләрне финанслау, тиешле фәнни тикшеренү институтларына һәм Татарстан халыкларының телләре буенча фәнни эшләр алып баручы югары уку йортларына ярдәм итү, массакүләм мәгълүмат чараларында төрле телләрне куллану өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләүче белгечләр әзерләү, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасын камилләштерү максатында халык мәгарифе системасын үстерү кебек юнәлешләрне һәм башкаларны күз алдында тота.

3. Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасының төп өлешен татар теленең яңарышы, саклануы һәм үсеше, аны һәрьяклап өйрәнү һәм камилләштерү турындагы бүлек тәшкил итә. Бу бүлек татар телендә мәктәпкәчә балалар тәрбияләү йортларын ачуны, татар телендә укыту системасын булдыру мәсьәләләрен хәл итүне, фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләүне, әдәбият, фән һәм сәнгать, телевидение һәм радиотапшырулар

үсешен, татар телендә китаплар, газета-журналлар бастыруны, сүзлекләр, дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият чыгаруны, шулай ук татар теле үсеше өчен кирәкле башка мәсьәләләрне хәл итүне күз алдында тота.

Дәүләт программасы татар теленең алга таба үсешен башлыча төрки телләр нигезендә алып барылуны күз алдында тота.

Татарстан Республикасы фәнни тикшеренү учреждениеләрендә, югары уку йортларында, архивларда, китапханәләрдә, музейларда Татарстан халыклары телләре фондларын һәм истәлекләрен ишәйтүне һәм саклауны, шулай ук аларны куллануны тәэмин итә.

Дәүләт татар халкының башка төбәкләрдәге вәкилләренә һәрьяклы рухи үсеш өчен кирәкле булган туган тел, мәдәният, гореф-гадәтләр һәм йолаларны саклауда һәм үстерүдә төрле ярдәм күрсәтә.

## II БҮЛЕК

### Татарстан халыкларының телләрен куллану буенча гражданнарның хокуклары

8 маддә. Аралашу телен сайлауга хокук

Татарстан Республикасы гражданнары аралашу телен ирекле рәвештә сайларга хокуклы.

9 маддә. Тәрбия һәм уку-укыту телен сайлауга хокук

1. Татарстан Республикасы гражданнары тәрбия һәм уку-укыту телен ирекле сайларга хаклы. Балаларга туган телне өйрәтү-ата-аналарның гражданлык бурычы.

2. Дәүләт Татарстан Республикасы территориясендә республиканың дәүләт телләрендә тәрбия-мәгариф учреждениеләре, тәрбия һәм укытуның башка рәвешләре системасын төзүне тәэмин итә һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыклар телләрендә тәрбияләү һәм укытуны оештыруга ярдәм итә.

3. Балаларны теге яисә бу телдә тәрбияләү һәм укыту буенча тәрбия-мәгариф учреждениеләрен сайлауга хокук ата-аналарга яисә, Татарстан Республикасы законнары нигезендә, аларны алмаштыручы затларга бирелә.

4. Мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә, гомуми белем мәктәпләрендә, урта, махсус урта һәм югары уку йортларында укыту теле Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

10 маддә. Татарстан Республикасы халыклары телләрен өйрәнү һәм укыту

1. Дәүләт Татарстан Республикасы гражданнарына туган телен һәм Татарстан Республикасының башка халыклары телләрен өйрәнү һәм укыту өчен шартларны тәэмин итә.

2. Татар һәм урыс телләре, Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак, мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә, гомуми белем мәктәпләрендә, урта һәм махсус урта уку йортларында бертигез күләмнәрдә өйрәнелә.

3. Дәүләт Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне тиешле фәнни тикшеренү учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында фәнни тикшерү өчен шартлар тудыра, Татарстан Республикасы дәүләт телләре буенча белгечләр әзерләүне тәэмин итә.

## III БҮЛЕК

## Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсенең югары органнарында Татарстан Республикасы халыклары телләрен куллану.

11 маддә. Татарстан Республикасы Югары Советында, Министрлар кабинетында, Президент аппаратында эш башкару теле

1. Татарстан Республикасы Югары Советында, Министрлар кабинетында, Президент аппаратында эш башкару татар һәм урыс телләрендә алып барыла.

2. Татарстан Республикасы Югары Советы сессияләрендә, Президиум һәм даими комиссияләр утырышларында Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берәрсендә, кирәк чакта, Татарстан Республикасының башка теләсә кайсы халык телендә чыгыш ясый ала, бу вакытта чыгышлар тәрҗемә ителергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив актларының проектлары Татарстан Республикасы Югары Советы сессиясенә һәм Югары Совет органнары карамагына татар һәм урыс телләрендә эшләнеп кертелә.

12 маддә. Татарстан Республикасы законнарын һәм башка хокукый актларны бастырып чыгару теле

Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Президиумы, Президент, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актларның текстлары татар һәм урыс телләрендә бастырып чыгарыла һәм алар тигез юридик көчкә ия була.

13 маддә. Татарстан Республикасында хакимият һәм башкарма органнарына сайлаулар, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар һәм референдумнар үткәрү теле

1. Татарстан Республикасында хакимият һәм башкарма органнарына сайлауларга, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга һәм референдумнарга әзерләнгәндә һәм аларны уздырганда Татарстан Республикасының дәүләт телләре, шулай ук әлеге Закон нигезендә башка телләр кулланыла.

2. Референдум бюллетеньнәре һәм сайлау бюллетеньнәре Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, шулай ук әлеге Законның 3 маддәсе нигезендә башка телләрдә эшләнә. Референдумнар һәм сайлаулар үткәрү буенча эш кәгазьләре татар һәм урыс телләрендә әзерләнә.

## IУ БҮЛЕК

### Татарстан Республикасы халыклары телләрен дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлегендә куллану

14 маддә. Дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшендә телләрне куллану

1. Татарстан Республикасының дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлегендә Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

2. Татарстан Республикасының татар яки урыс телләрен белмәгән гражданнарына дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары утырышында, киңәшмәсендә, җыелышында үзләре белгән телдә чыгыш ясау хокукы бирелә. Кирәк чакта, тиешле тәрҗемә тәэмин ителә.

3. Дәүләт органнарында, предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында утырыш, киңәшмә, җыелыш алып барыла торган телне белмәгән Татарстан Республикасы гражданнары, кирәк чакта, аларга яраклы телгә тәрҗемә белән тәэмин ителә.

4. Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, учреждениеләренә һәм оешмаларына тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән туган телләрендә яки Татарстан Республикасының үзләре белгән теләсә кайсы башка телендә мөрәҗәгать итәргә хаклы.

5. Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт органнарына, предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына җибәрелгән тәкъдимнәргә, гаризаларга һәм шикаятьләргә җаваплар мөрәҗәгать итүче кулланган дәүләт телендә бирелә.

I5 маддә. Рәсми эшләрне башкаруда телләрне куллану

I. Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт органнарында, учреждениеләрендә һәм оешмаларында рәсми эшләр Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә алып барыла.

2. Документлар /бланклар, мөһерләр, штамплар, штемпельләр/ текстлары һәм дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары атамалары язылган такталар /вывескалар/ татар һәм урыс телләрендә эшләнә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт телләрен белмәгән халыклар вәкилләре күпләп урнашкан төбәктәге дәүләт органнарында, учреждениеләрдә һәм оешмаларда рәсми эшләр әлеге төбәктәге күпчелек халык телендә алып барылырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасында гражданның шәхесен раслаучы рәсми документлар яки аның турындагы белешмәләр /паспортлар, туу, өйләнешү һәм үлү турында таныклыклар, хезмәт кенәгәләре, уку йортларын тәмамлау турында аттестатлар һәм дипломнар, хәрби билетлар һәм башка документлар/, кеше исемен язудагы милли гореф-гадәтләрне истә тотып, татар һәм урыс телләрендә тутырыла.

I6 маддә. Рәсми хатларда телләрне куллану

Татарстан Республикасында дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмаларының үзара хат алышуы һәм үзара рәсми мөнәсәбәтләрнең башка рәвеше татар һәм урыс телләрендә алып барыла.

I7 маддә. Татарстан Республикасында суд эшләрен башкаруда телләрне куллану

Татарстан Республикасында суд эшләренең теле гражданлык-процессуаль, җинаять-процессуаль һәм арбитраж-процессуаль законнар җыелмасы нигезендә билгеләнә.

18 маддә. Нотариаль эшләрне башкаруда телләрне куллану

Дәүләт нотариаль контораларында һәм нотариаль вазифаларны башкаручы башка дәүләт органнарында нотариаль эшләр, мөрәҗәгать итүче гражданның таләбе буенча, Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берәрсендә алып барыла.

19 маддә. Массакүләм мәгълүмат чаралары теле

I. Республика газеталарын һәм журналларын нәшер итү , телевидение һәм радио тапшыруларын алып бару татар һәм урыс телләрендә гамәлгә ашырыла. Газета һәм журналлар гамәлгә куючылар ихтыяры белән шулай ук башка телләрдә нәшер ителергә мөмкин.

2. Массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге территориянең күпчелеген тәшкил итүче башка халык телләре кулланылырга мөмкин.

3.Кино һәм видеопродукцияләрне тәрҗемә иткәндә һәм дубляж ясаганда дәүләт телләре һәм, халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләр кулланыла.

20 маддә. Сәнәгать, элемтә, транспорт һәм энергетика өлкәләрендә кулланыла торган телләр

I. Татарстан Республикасының бөтен территориясендә сәнәгать, транспорт, элемтә һәм энергетика өлкәләрендә урыс һәм /яки/ татар телләре кулланыла.

Тимер юл, һава, су юлы, торбаүткәргеч транспорты, элемтә һәм энергетикадагы оператив элемтәдә урыс теле кулланыла.

2. Сәнәгать, элемтә, транспорт һәм энергетика өлкәләрендә, татар һәм урыс телләре белән рәттән, җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләр дә кулланылырга мөмкин.

21 матдә. Хезмәт күрсәтү өлкәсендә һәм коммерция эшчәнлегендә кулланыла торган телләр

Дәүләт хезмәт күрсәтү өлкәсендә һәм коммерция эшчәнлегендә Татарстан Республикасының дәүләт телләре, ә аерым территорияләрдәге профессиональ эшчәнлек өчен зарури күләмдә анда яшәүче башка халыклар теле кулланыла. Телне белмәү сылтавы белән гражданнарга хезмәт күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми һәм бу гамәлне кылучылар закон нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

22 матдә. Фән өлкәсендә телләр

Татарстан Республикасында фәнни эшләрнең теле ирекле рәвештә сайлана.

Татар телендә басыла торган көндәлек фәнни басмаларда фәнни нәтиҗәләрнең /резюме/ төп төшенчәләрен бәян итү урыс телендә, кирәк очракта, берәр чит телдә бирелә. Урыс телендә яки башка телдә басыла торган көндәлек фәнни басмаларда кыскача нәтиҗәләр /резюме/ татар телендә һәм, кирәк очракта, берәр чит телдә бирелә.

23 матдә. Мәдәният өлкәсендә телләр

1. Татар милли мәдәниятен баету һәм татарларны башка халыклар мәдәнияте үсеше белән киңрәк таныштыру максатында, Татарстан Республикасы матур әдәбият, сәяси, фәнни һәм башка әдәбият басмаларын татарчага тәрҗемә итүне һәм бастыруны, шулай ук фильмнарны һәм башка аудиовизуаль әсәрләрне татарчага тәрҗемә итеп халыкка күрсәтүне тәэмин итә.

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның мәдәниятен баету максатында, дөнья мәдәнияте әсәрләре татар һәм урыс телләренә тәрҗемә ителә.

2. Башка халыкларны татар мәдәнияте үсеше белән таныштыру максатында, игътибарга лаеклы татар әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итеп, аларны бастыру һәм ишәйтү тәэмин ителә.

3. Мәдәни мирасны өйрәнү һәм кулланышка кертү максатыннан, татар мәктәпләрендә, татар теле өйрәнелә торган югары һәм махсус урта уку йортларының татар филологиясе һәм тарих факультетларында һәм бүлекләрендә,уку предметы буларак, гарәп графикасы нигезендә иске татар язма телен өйрәнү өчен мөмкинлекләр тудырыла.

Республикада гарәп һәм латин графикаларын өйрәнергә теләүчеләр өчен шартлар тудырыла: фәнни-педагогик кадрлар әзерләнә, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре, әдәби-тарихи истәлекләр бастырыла.

## У БҮЛЕК

### Географик атамаларның һәм язмаларның, топографик билгеләмәләрнең һәм юл күрсәткечләрнең теле

24 маддә. Географик атамаларның һәм язмаларның,топографик билгеләмәләрнең һәм юл күрсәткечләрнең телен билгеләү тәртибе

Татарстан Республикасында географик атамалар һәм язмалар, топографик билгеләмәләр, юл күрсәткечләре татар һәм урыс телләрендә, шулай ук, җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләрдә эшләнә.

25 маддә. Язмаларны, топографик билгеләмәләрне һәм юл күрсәткечләрен эшләү һәм урнаштыру буенча башкарма хакимият органнарының вазифалары

Башкарма хакимият органнары язмаларны, топографик билгеләмәләрне һәм юл күрсәткечләрен урнаштыруны тәэмин итә һәм аларны Татарстан Республикасы законнарына, халыкара стандартларга туры китереп эшләүгә һәм тиешле тәртиптә тотуга җаваплы була.

26 маддә. Территорияләрнең, торак пунктлар-ның һәм башка объектларның исемнәре һәм аларның исемнәрен алыштыру

1. Территорияләрнең, торак пунктларның һәм башка объектларның исемнәре һәм аларны алыштыру Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы халыклары телләрендә башкарыла.

2. Торак пунктларның исемнәрен бозып ату рөхсәт ителми.

## VI БҮЛЕК

## Татарстан Республикасының чит дәүләтләр, халыкара оешмалар белән мөнәсәбәтләрендә телләрне куллануы

27 маддә. Татарстан Республикасының чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар белән мөнәсәбәтләрендә телләрне куллануы

1. Татарстан Республикасының чит ил вәкилләре, Татарстан Республикасының тышкы сәяси, тышкы икътисади һәм башка учреждениеләре эшчәнлеге татар, урыс телләрендә һәм бәйләнешкә кергән дәүләт телендә алып барыла.

2. Татарстан Республикасы исеменнән төзелә торган аңлашманамәләр, килешүләр һәм башка халыкара актлар татар һәм урыс телләрендә һәм килешүче икенче як телендә яки ике якның үзара килешүләре буенча башка телләрдә эшләнә.

3. Татарстан Республикасы исеменнән башка илләр, халыкара оешмалар вәкилләре белән сөйләшүләрдә татар яки урыс телләре һәм, ике якның үзара килешүләре буенча һәм халыкара килешүләр нигезендә, башка телләр кулланыла.

287

УП БҮЛЕК

Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

28 маддә. Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

Юридик һәм физик затлар Татарстан халыклары телләре турында Татарстан Республикасы законнарын бозган гамәлләре өчен Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавапка тартылалар.

Татарстан Республикасы Президенты — М.ШӘЙМИЕВ

Казан шәһәре,
1992 елның 8 июле
№ I560-XП